**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

08.04.2022 № 135

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү иректе җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсе җитәкче органнары составына кандидатуралар турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсе җитәкче органнары составына кандидатуралар турында» 2018 елның 23 маендагы 198 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Леонов Владимир Александровичны – Татарстан Республикасы спорт министрын;»;

тугызынчы – унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сөләйманов Тимур Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улын – Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Гыйльманов Рафаил Вәли улын – Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретарен;».

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ